**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

**Боерык**

04.07.2013 ел Казан ш. №21-53-35

**Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемендә түләтү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пунктына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясындагы 4 пунктына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 11 июнь, 2009 ел, №51-н боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын бюджетлар керемендә түләтү тәртибенә карата гомуми таләпләргә туры китереп, боерык бирәм:

1.Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемендә түләтү тәртибен расларга.

2.Татарстани Республикасы Финанс министрлыгының Казанчылык департаментына бу боерыкны Татрстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алырга.

3.Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Г.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 04.07.2013 ел, №21-53-35 боерыгы белән расланды

**Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтү**

**ТӘРТИБЕ**

1. Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемενә түләтүнең бу Тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пунктына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясындагы 4 пунктына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 11 июнь, 2009 ел, №51-н боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын бюджетлар керемενә түләтү тәртибенә карата гомуми таләпләргә туры китереп эшләнде.

Бу Тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән, әмма хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 апреленә кадәр күчерелмәгән, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә (алга таба – максатчан средстволар) алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемενә түләтү тәртибен билгели.

2.Бу Тәртипне тормышка ашыру максатында:

Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлар) булып Татарстан Республикасы Бюджет турында Законы нигезендә үзләренә җирле бюджетлардан максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәр коды (2 18 00000 00 0000 151) билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары (алга таба – калдыкларны кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторлары) тора;

Максатчан средстволарны кире кайтару буенча муниципаль бюджет керемнәренең баш администраторлары (администраторлар) булып җирле бюджет турында карар нигезендә үзләренә җирле бюджетлардан максатчан средстволар калдыкларын кире кайтару буенча керемнәр коды (2 19 00000 00 0000 151) билгеләнгән җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары (алга таба – калдыкларны кире кайтару буенча керемнәр администраторлары) тора.

3.Максатчан средстволарның файдаланылмый калган калдыклары хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 апреленә кадәр Татарстан

Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татрстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – Татарстан Республикасы буенча ФКИ), бу Тәртипкә №1 кушымта нигезендәге форма буенча, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын (алга таба – Боерык) җибәрә.

Боерыкка кушымтада (боерыкның аерылгысыз өлеше булып тора) күрсәтелә:

калдыкларны кире кайтарудан керемнәрнең тиешле баш администраторлары атамалары, аларның салым түләүче идентификация номеры (алга таба – ИНН) салым учетына кую сәбәпләре коды (алга таба – КПП), бюджет средстволарының баш администраторларының кодлары, Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән максатчан средстволар буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары кодлары, алынган максатчан средстволар буенча Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификация кодлары, аларга туры килә торган, кире кайтару буенча керемнәр администраторларының атамалары суммалары, максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәрнең туплану урыны буенча административ-территориаль бүленеш объектларының Гомумроссия классификаторы (алга таба – ОКАТО (ОКТМО), ИНН, КПП, шулай ук лицевой счетлар номерлары.

Боерык имзаланганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча, гамәлдәге закон нигезендә үтәү өчен, Татарстан Республикасы буенча ФКИгә җибәрелә.

Боерык күчермәсе (аннан өземтә) имзаланганнан соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан калдыкларны кире кайтарудан керемнәрнең тиешле баш администраторларына җибәрелә.

Калдыкларны кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторлары Боерык алынганнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча Боерык күчермәсен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең финанс органнарына җибәрә.

4.Кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторы (средстволарны баш бүлүче) 20 ___ елның 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматларны, бу Тәртипкә № 2 кушымта нигезендәге формада, хисап елыннан соң килүче финанс елының 10 апреленә кадәрге срокта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының республика бюджеты учеты һәм хисап бүлегенә (алга таба – учет һәм хисап бүлеге) тапшыра.

Калдыкларны кире кайтару буенча керемнәр администраторлары (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс органнары) хисап елыннан соң килүче финанс елының 10 апреленә кадәрге срокта учет һәм хисап бүлегенә, бу Тәртипкә №3 кушымта нигезендәге формада, 20 ___ елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматлар тапшыра.

7.Учет һәм хисап бүлеге 20 ___ елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматларны тикшереп, хисап елыннан соң килүче финанс елының 20 апреленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының төбәкләр бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлегенә тапшыра.

8.Боерык, кушымта белән, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының төбәкләр бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге тарафыннан, 20 ___ елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматлар нигезендә, файдаланылмый калган максатчан средстволар калдыкларын хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемен күчермәгән Татарстан Республикасы һәр муниципаль берәмлеге буенча рәсмиләштерелә.

9.Файдаланылмый калган максатчан средстволарны түләтү Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасына керемнәр учеты һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү тәртибе (Россия Федерацясе Финанс министрлыгының 5 сентябрь, 2008 ел, №92н боерыгы белән расланган) нигезендә, үзләре тарафыннан блигеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән Кире кайтаруга заявкалар буенча (КФД буенча форма коды 0531803) хәл ителә.

10.Файдаланылмый калган максатчан средстволарны кире кайтару Татарстан Республикасы буенча ФКИ тарафыннан, Боерык күчермәсе алынганнан соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, средстволар калдыклары булганда, аларны максатчан средстволарны кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторларына (администраторлар) ачылган бюджет керемнәре администраторының лицевой счетларында чагылдырып, “Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетлары арасында Федераль казначылык органнары тарафыннан бүленә торган керемнәр” № 40101 счетына хәл ителә.

11.Агымдагы финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлардан, әлеге трансфертларга ихтыяҗ булганда, шушы

ук максатларга, кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторы карары, бюджетара трансфертлар буенча бюджетлар арасында исәп-хисаплар буенча рәсмиләштерелеп, кире кайтару буенча керемнәрнең тиешле администраторларына җибәрелгән уведомлениеләр (ОКУД буенча форма коды 05034817) нигезендә, чираттагы финанс елында файдаланылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 04.07.2013 ел, № 21-53-35 боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләтү тәртибенә № 1 кушымта

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

**Боерык**

"___" ____________ 20__ ел N _______

**Казан ш.**

_______________________________________________________

**(Татарстан Республикасы муниципаль бермәлеге атамасы)**

бюджетыннан, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләтү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясындагы 5 пунктына, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясындагы 4 пунктына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 11 июнь, 2009 ел, №51-н боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын бюджетлар керемена түләтү тәртибенә карата гомуми таләпләргә туры китереп, боерык бирәм:

1. _______________________________________________________

**(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы)**

бюджетыннан, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын, ______ сум ____ тиен күләмендә, түбәндәге реквизитлар буенча, бу Боерыкка кушымта нигезендә түләтергә һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчертергә:

Реквизиты счета УФК по Республике Татарстан (Министерство финансов Республики Татарстан, л/счет 04112001110):
номер счета 40101810800000010001
ИНН 1654019570, КПП 165501001
ГРКЦ НБ Республики Татарстан Банка России г. Казань,

БИК 049205001,
ОКАТО (ОКТМО) 92401000000,

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанс органы реквизитлары.

______________________________________________________________________:
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы)

| | |
|---|---|
| ИНН | |
| КПП | |

Министр ________________ ____________________________________________
(имза) (тулы имза)

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының**
**04.07.2013 ел, № 21-53-35 боерыгына кушымта**

| Ммксатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторы | | | | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код * | | Татарстан Республикасы бюджеты керемнә түләтелерегә тиешле сумма (сум.) | Кире кайтару буенча керемнәр администраторлары | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атамасы | ИНН | КПП | бюджет классификациясе буенча бүлек коды | Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән максатчан средстволар буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьясы | Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган максатчан средстволар буенча җирле бюджет керемнәре | | Атамасы | Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәрне туплау урыны буенча муниципаль берәмлекнең ОКАТО (ОКТМО) коды | ИНН | КПП | Лицевой счеты |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | х | х | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
җаваплы эш башкаручысы ____________ __________ ______________________ __________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы) (телефоны)

*** Хисап финанс елының Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код күрсәтелә.**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 04.07.2013 ел, № 21-53-35 боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтү тәртибенә № 2 кушымта

20 ___ елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматлар

**"___" ___________ 20__ ел**

________________________________________________________

**(максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәрнең баш администраторы)**

Үлчәү берәмлеге: сум.

| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге атамасы | Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы | | | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код * | | Файдаланылмаган максатчан средстволар калдыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ИНН | КПП | бюджет классификациясе буенча бүлек коды | бирелгән максатчан средстволар буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьясы | алынган максатчан средстволар буенча муниципаль берәмлек бюджеты керемнәре | 01.01.20__ елга | Шул исәптән | |
| | | | | | | | 01.04.20__ елга Татарстан Республикасы бюджеты кеременә алынган | Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылмаган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек буенча барлыгы | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Җәмгысы: | | | | | | | | |

* Хисап финанс елының Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код күрсәтелә.

Җитәкче ___________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Баш бухгалтер ___________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Җаваплы эш башкаручы___________ __________ ___________________ ________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы) (телефоны)

"___" ____________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 04.07.2013 ел, № 21-53-35 боерыгы белән расланган Максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган, әмма файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты керемenә түләтү тәртибенә № 3 кушымта

20 ___ елның 1 гыйнварына файдаланылмаган, максатчан билгеләнешле булып, субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган бюджетара трансфертлар калдыклары турында мәгълүматлар

**"___" ____________ 20__ ел**

**______________________________________________**

**(максатчан средстволар калдыкларын кире кайтару буенча керемнәрнең баш администраторы)**

**ИНН ___________________, КПП__________________**

Үлчәү берәмлеге: сум.

| Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы атамасы | Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтару буенча бюджет керемнәренең баш администраторы | | | Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код * | | Файдаланылмаган максатчан средстволар калдыгы | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан керемнәрне туплау урыны буенча муниципаль берәмлекнең ОКАТО (ОКТМО) коды | Лицевой счеты | бюджет классификациясе бүлеге коды | Бирелгән максатчан средстволар буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьясы | Алынган максатчан средстволар буенча муниципаль берәмлекнең бюджеты керемнәре | 01.01.20__ елга | шул исәптән | |
| | | | | | | | 01.04.20__ елга Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелгән | Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылмаган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Максатчан средстволар калдыкларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторы буенча барлыгы | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Җәмгысы: | | | | | | | | |

* Хисап финанс елының Россия Федерациясе бюджет классификациясе буенча код күрсәтелә.

Җитәкче ___________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Баш бухгалтер ___________ ____________________
(имза) (тулы имза)

Җаваплы эш башкаручы____________ ___________ ____________________ _________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы) (телефоны)

"___" ____________ 20__ ел